**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Кодаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге составына керүче Кызыл Чишмә авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карар**

2020 елның 21 ноябре, № 1
Кызыл Чишмә авылы, Октябрь ур., 8

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә. Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Кызыл Чишмә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, 2021 елда үзара салым кертүгә 300,00 сум күләмендә билгеләү белән килешәсезме? мәсьәләсе буенча 2020 елның 21 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде. Түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җыелган акчаларны тоту:

1) Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге составына керүче Кызыл Чишмә авылы торак пункты юлларын ремонтлау өчен

«ӘЙЕ», «ЮК»

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 48 кеше кертелгән. Җыенда катнашучылар саны 25 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашучы 25 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;

халык җыенында катнашкан 0 кеше тыелып торды.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:
1.Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Кызыл Чишмә авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип таныргa.

2. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Кызыл Чишмә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, 1 төркем инвалидлардан, өч һәм аннан күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләрдән тыш, 2021 елда үзара салым кертүне 300,00 сум күләмендә билгеләү белән килешәсезме?( Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Кодаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге составына керүче Кодаш авылы торак пункты юлларын ремонтлау өчен) дигән сорау буенча карар кабул ителде.

3. Әлеге карарны Кызыл Чишмә авылы торак пунктының махсус мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми порталында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә. http://bugulma.tatar.ru (район турында бүлегенең Кодаш авыл җирлеге»бүлекчәсе).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Бөгелмә муниципаль районы
Кодаш авыл җирлеге башлыгы Г. Ә. Хәйсарова